БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16» 11 2021 ел №348

2022 елга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

«Мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Татарстан Республикасының туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләренең һәм балаларга өстәмә белем бирү күппрофильле мәгариф учреждениеләренең норматив чыгымнарын нормативларны исәпләү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1.2022 елга расларга:

1 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендә өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга кушымта итеп бирелгән норматив чыгымнарын; туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентын 0,5 күләмендә.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә

балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә;

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары гамәлдә булган чор дәвамында хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын индексацияләү белән бер үк вакытта яңадан карау.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча халыкка җиткерергә http://baltasi.tatarstan.ru.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф. Хәйретдинов

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2021 елның 16.11
348 номерлы карары белән
расланган

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү күппрофильле мәгариф оешмаларының**

**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАРЫ**

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль урнашу | Норматив чыгымнар, бер укучыга бер елга сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | беренче уку елы | икенче уку елы | өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Сәнгать-эстетик | шәһәр җирлеге | 5 569 | 10 314 | 12 376 |
| | авыл җирлеге | 5 970 | 11 055 | 13 266 |
| Физкультура-спорт | шәһәр җирлеге | 5 468 | 10 126 | 12 151 |
| | авыл җирлеге | 5 868 | 10 867 | 13 041 |
| Техник иҗат | шәһәр җирлеге | 5 873 | 10 876 | 13 051 |
| | авыл җирлеге | 6 273 | 11 617 | 13 940 |
| Туризм-туган якны өйрәнү | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Экология-биология | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Хәрби-патриотик | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Социаль-педагогик | шәһәр җирлеге | 5 266 | 9 751 | 11 702 |
| | авыл җирлеге | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Социаль-икътисади | шәһәр җирлеге | 5 266 | 9 751 | 11 702 |
| | авыл җирлеге | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Табигый-фәнни | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |